| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерже муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2023 Кадрәк авылы № 2

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әгерже муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен “Кадрәк авыл җирлеге” Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кадрәк авылы Ленин, Сосновая, Полевая, Заречная, Яшьләр урамнары өчен вак таш сатып алу һәм җәю);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-

майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, ремонтлау һәм алыштыру һәм урам яктырту өчен материаллар сатып алу)ремонтлау;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар (отвал) сатып алу, үлән әзерләү өчен бензин чалгычлары сатып алу, куакларны кисү өчен бензин кискече сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, транспортлау һәм халыкка су бирү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадрәк авылы, Ленин урамы, 55 йорт, авыл мәдәният йорты территориясендә.

4. Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.А. Михайлов